**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ КЫЯЗЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**КАРАР**

**№15** **15.06.2015 ел**

Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауны билгеләү турында

"Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 10 статьясындагы 3, 7 пунктларына, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2 өлешенә, 105 статьясындагы 1 өлешенә, «Иске Кыязлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясына ярашлы рәвештә, Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауны 2015 елның 13 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча «Сельская Новь» район газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга. http://Aksubayevo.tatarstan.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы рәисе Заһидуллин Илшат Минсабир улына йөкләргә.

Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы
Совет рәисе: И. М. Заһидуллин